КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 27 апрель г.Казань № 398

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумталралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 февраль, 171 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 февраль, 171 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2014 ел, 22 май, 347 нче; 2015 ел, 14 август, 589 нчы, 2016 ел, 23 июнь, 434 нче, 2021 ел, 21 апрель, 266 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 19 статьясы, «Татарстан Республикасында җир асты

байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 13 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир кишәрлекләре чикләрендә булган гомумтаралган файдалы казылмалардан, җир асты суларыннан, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә җир асты корылмаларын төзүнең үз ихтыяҗлары өчен файдалану тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир кишәрлекләре чикләрендә булган гомумтаралган файдалы казылмалардан, җир асты суларыннан, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә җир асты корылмаларын төзүнең үз ихтыяҗлары өчен файдалану тәртибендә:

1 пунктның беренче абзацында «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 29 статьясы» сүзләрен «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 13 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның беренче абзацында «җир кишәрлекләрен арендага алучылар» сүзләреннән соң «аларның категориясенә бәйсез рәвештә» сүзләрен өстәргә;

3 пунктның дүртенче абзацында «WGS-84 координатлары системасында» сүзләрен «ГСК-2011 координатлары системасында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин